**ГЛАВА
БОЛЬШЕКАБАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ**

Кәньяк урамы, 1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**2023елның «22» марты** **4 номер**

# КАРАР

## Җир кишәрлеген файдалануның шартлыча рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 нчы маддәсе, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының “Олы Кабан авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 20 нче маддәсе нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, карар бирәм:

1. Кадастр номеры 16:24:160201:340, мәйданы 1980 кв. м булган , ТР, Лаеш муниципаль районы, Кече Кабан авылы, Центральная ур. адресы буенча урнашкан җир кишәрлеген «шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару»дан”культ бинасы”на-шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә 2023 елның 14 апрелендә 15.00 сәгатьтә Олы Кабан мәдәният йорты бинасында ТР, Лаеш муниципаль районы, Кече Кабан авылы, Көньяк урамы, 1 нче йорт адресы буенча ачык тыңлаулар уздырырга.
3. Ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне 2023 елның 14 апреленә кадәр Татарстан Республикасы Лаеш районы Кече Кабан авылы, Көньяк урамы, 1 адресы буенча язма рәвештә яисә факс (8843 78) 4-22-02) буенча җибәрергә.
4. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башлык –ТР
Лаеш муниципаль районы
Олы Кабан авыл җирлеге
Советы рәисе** **Р.Ш.Илһамов**